**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 апрель № 254

г. Казань

«Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорриясенең потенциаль резидентларын җәлеп итү чаралары турында

Татарстан Республикасы икътисад министры А.А.Здуновның «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе статусын алуга заявкалар тапшыру тәртибе һәм шартлары турында, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Т.И.Миңнуллинаның резидентларны җәлеп итү буенча үткәрелә торган эш хакында, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиле Н.А.Кропотованың потенциаль резидентларны урнаштыру өчен булган мәйданнар турында һәм Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе Ш.Р.Агеевның потенциаль резидентларны җәлеп итү хакында докладларын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы белән берлектә, очрашулар үткәргәндә, форумнарда, күргәзмәләрдә һәм башка иҗтимагый чараларда катнашканда аларда катнашучыларга «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына бирелә торган мөмкинлекләр турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү рөхсәт ителә торган масштаблы инвестицион проектлар туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 ел, 7 декабрь, ПУ-1170 нче Указына, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына сатулар үткәрмичә арендага җир кишәрлекләре бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, масштаблы инвестицион

проектлар туры килергә тиешле таләпләр өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр кертергә.

3. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасының тармак министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын җәлеп итүне һәм озата баруны, шулай ук үткәрелә торган эш нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Инвестицион советы һәм аның президиумы утырышларында карап тикшерүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

10 көн эчендә Татарстан Республикасының моношәһәрләре территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре белән идарә итүнең оештыру структурасы буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын җәлеп итү эшчәнлеге нәтиҗәләрен тасвирлый торган күрсәткечләр өстәү хакында тәкъдим кертергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары өчен кадрларда ихтыяҗны билгеләү һәм аларны әзерләү (яңадан әзерләү) системасын эшләргә;

«КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте белән берлектә, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары өчен «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең бушый торган производство мәйданнарыннан файдалануны киңәйтү мөмкинлеген карарга;

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, квартал саен Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашындагы киңәшмәләрдә «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе эшчәнлеге һәм аны үстерү мәсьәләләрен карап тикшерергә.

5. Тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнарына һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга, инвестицион проектларны тормышка ашырганда, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына максималь рәвештә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

6. Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, бер ай эчендә Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашында «Развитие» сәнәгать

паркы инженерлык инфраструктурасы төзелешен тәмамлау мәсьәләсе буенча киңәшмә оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына инвентарьлаштыру үткәрергә һәм, инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен әлеге мәйданнарда файдаланылырга мөмкин булган электр белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү челтәрләре, суүткәргеч, канализация торышы хакындагы мәгълүматны кертеп, алга таба әлеге мәгълүматларны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырып һәм яңартып, республика, муниципаль, хосусый милектәге буш (файдаланылмый торган) җир кишәрлекләренең, күчемсез мөлкәт объектларының мәгълүматлар базасын төзергә тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, бу карарның 7 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны җыюны, гомумиләштерүне, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгының рәсми сайтында урнаштыруны һәм яңартуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасының тармак министрлыкларына, потенциаль резидентларның инвестицион проектлары буенча эксперт бәяләмәсен әзерләгәндә, гамәлдәге базар һәм конкурентлык, сату һәм чимал белән тәэмин итүне анализлау өлешендә инвестицион проектларның бизнес-планнары нигезләнгән булуына, шулай ук гамәлдәге яки ачыла торган шундый производстволарның алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе барлыгына игътибар итәргә.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына бирелә торган мөмкинлекләр турында масскакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, дәүләт мәгълүмат ресурсларында, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты булырга теләгән инвестор гамәлләренең һәркем файдалана алырлык «юл картасы»н кертеп, «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына бирелә торган мөмкинлекләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

12. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\254.docx